**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«14» февраль 2025 ел** Күзкәй авылы № 2-1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел срокка расларга (кушымта нигезендә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын кертеп, график сурәте белән бергә, 5 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Күзкәй авылы, Әхмәтшин ур., 20 йорт (административ бина);
Күзкәй авылы, Муса Җәлил ур., 35 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы);
Югары Байлар авылы, Советская ур., 29 йорт (авыл клубы бинасы).

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Э.Р. Гәрәев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй елның 14 февралендәге 2-1 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Күзкәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Садовая ур. | 82 |
| 2 | 2 нче бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Комсомольская ур. | 81 |
| 3 | 3 нче бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Әхмәтшин ур. | 96 |
| 4 | 4 нче бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Муса Җәлил ур., Мирная ур. 22-45 й. | 88 |
| 5 | 5 нче бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Молодежная ур. 6-15А йортлары, Яңа Байлар авылы Октябрьская ур., Ромашка бакчачылык коммерциясез ширкәте | 93 |
| 6 | 6 нчы бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Молодежная ур. 1-5 й., Яңа Байлар авылы Алмалы ур. | 79 |
| 7 | 7 нче бермандатлы сайлау округы | Күзкәй авылы Мирная ур. 1-21 й., Пионерская ур., Иске Байлар авылы 1 нче Нагорная ур., 2 нче Нагорная ур. | 82 |
| 8 | 8 нче бермандатлы сайлау округы | Иске Байлар авылы Гагарин ур. | 82 |
| 9 | 9 нчы бермандатлы сайлау округы | Югары Байлар авылы Лесная ур., ул. Г. Шәрип ур., Новая ур., 1 нче Новая ур., 2 нче Новая ур. | 95 |
| 10 | 10 нчы бермандатлы сайлау округы | Югары Байлар авылы Советская ур., Братская ур. | 94 |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫН САЙЛАУЛАРНЫ УЗДЫРУ ӨЧЕН
БЕРМАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЛАРЫ СХЕМАСЫНЫҢ ГРАФИК СУРӘТЕ

Тукай муниципаль районы

Күзкәй авыл җирлеге

Масштаб: 1:10000

